СОВЕТ
НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17 август 2023 ел.** Түбән Урысбага **№ 136**

Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 41 номерлы карары (Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августындагы 79 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 № 498-ФЗ Федераль законнар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 41 номерлы карары белән расланган Түбән Урысбага авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августындагы 79 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

1 нче кушымта
Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре

**Исемлек**

**ТР Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗасыз кайтару тыела торган урыннар"**

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Зират.».

2. Хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге башлыгы;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

Түбән Урысбага авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе Х.Х.Сибгатуллин.